**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы Советы**

# КАРАР

№ 253 04.06.2020 ел.

Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында хезмәт (вазифа) үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында Нигезләмә» 2018 елның 13 июлендә кабул ителгән 147 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Аксубай муниципаль районы Советының 13.07.2018 ел, №147 карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.21 пунктында сүзтезмә «, ә кирәк булганда-кичекмәстән» төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatar.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе: К. К. Гилманов